**Җиденче февраль.**
**Сыйныф эше.**
**Бүлем һәм тәртип саны, аларның кулланылышы.**

**Бирем. Цифрлар белән бирелгән саннарны сүзләр белән языгыз һәм җәя эчендә бирелгән төркемчәләргә куегыз.**

1.Алмаз башыннан 100 (чама саны), 1000 (чама саны) хәлләр үтте.(В.Н.)

2.Әбугалисина 10 (микъдар саны) яшендә үк инде алгебраны, геометрияне, хәтта философияне белгән.

3.Язуны ул 1 (тәртип саны) класстан ук яратмады.(М.М.)

4.Кергән бер кешегә 5 (бүлем саны), 10 (бүлем саны) сум акча бирә башлады. (М.М.)

5. 1(җыю саны) сөйли, 2(җыю саны) тыңлый, 2(җыю саны) карап тора.

1. Менә 3 (тәртип саны) җәй инде, су буйларын 2 (тәртип саны) 1 (микъдар саны) музыка үз канаты астына алды.(Г.А.)

2. 3, 4 (чама саны) көн ара белән кайткан абыйлар киткәндә бергә китteләр.(Г.А.)

3. Тегеләр 5 (җыю саны), ә без 10 (җыю саны) идек. (Г.М.)

4. Солдатларга 9 (бүлем саны) тезелергә кушылды.

## Бирем. Саннарның ясалышы ягыннан төрен билгеләгез.

*1 вариант*

**Туксан бер агач**

**Унсигез кыз**

**Кырык бакча**

**Җиде – сигез алма**

*2 вариант*

**Унтугыз егет**

**Өч йөз ике каз**

**Өчәр – дүртәр өстәл**

**Миллион теләк**

**БИРЕМ.** **Сүзләр эченнән сан тап.**

**Алтын, тун, кунак, йөзек, көч, бишек, фикер, бертуган.**

**БИРЕМ.Табылган саннардан тәртип һәм бүлем саннары ясап языгыз.**

**Өй эше:Микъдар, тәртип һәм бүлем саннарын файдаланып, «Алма бакчасы» темасына кечкенә күләмле инша языгыз.**

